**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«22» апреля 2019 ел №2/4

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетына Бәтке авыл җирлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.5 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Бәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетына Бәтке авыл җирлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны бирү тәртибен кушымтадагыча расларга.
2. 2019 елның 1 январеннән әлеге карар көчен гамәлгә кертергә.
3. Әлеге карарны авыл җирлегендә мәгълүмати стендларда урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык һәм хокук тәртибе даими комиссиясенә йөкләргә.

Бәтке авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе М.А Ионычев

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советының 2019 елның ______________ ____санлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетына Бәтке авыл җирлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны бирү тәртибе**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетына Бәтке авыл җирлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны бирү тәртибе (алга таба – тәртип) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.5 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 14, 15 маддәләре нигезендә эшләнгән һәм Тукай муниципаль районы (алга таба – муниципаль район) бюджетына Бәтке авыл җирлеге (алга таба – авыл җирлеге) бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны бирү очракларын, шартларын һәм тәртибен билгели.

2. Башка бюджетара трансфертларны бирү очраклары

2.1. Муниципаль район бюджетына авыл җирлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар түбәндәге очракларда бирелә:

1) төзелгән килешүләр нигезендә авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләр өлешен гамәлгә ашыруга, аларны муниципаль район дәрәҗәсенә тапшырганда;

2) авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килгән чыгым йөкләмәләрен уртак финанслау максатларында;

3) җирлекнең хокукый актларында каралган башка максатларга.

3. Башка бюджетара трансфертларны бирү шартлары

3.1. Муниципаль район бюджетына авыл җирлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар әлеге тәртипнең 2.1 пункты 1-3 пунктчаларында каралган очракларда муниципаль районның җирле үзидарә органнары тарафыннан салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе бюджет законнарын үтәү шартында бирелә.

3.2. Авыл җирлеге бюджетыннан муниципаль район бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү үз керемнәре һәм авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары хисабына тормышка ашырыла.

3.3. Башка бюджетара трансфертлар средстволары күләме авыл җирлеге бюджеты турында муниципаль берәмлек Советы карары белән расланган әлеге максатларга средстволар күләменнән артып китә алмый.

## 4. Башка бюджетара трансфертларны бирү тәртибе

4.1. Әлеге Тәртипнең 2.1 пункты 1-3 пунктчаларында каралган очракта муниципаль район бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү өчен нигез булып агымдагы финанс елына җирлек бюджетында каралган сумма чикләрендә муниципаль район Башкарма комитеты һәм авыл җирлеге Башкарма комитеты арасында төзелә торган килешү тора.

4.2. Муниципаль район бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешү түбәндәге төп нигезләмәләрне үз эченә алырга тиеш:

а) башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

б) башка бюджетара трансфертларны бирү һәм тоту шартлары;

в) башка бюджетара трансфертлар бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) башка бюджетара трансфертларны бирү сроклары;

д) башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе;

е) башка бюджетара трансфертларны бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартлар үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе;

ж) башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе;

з) агымдагы финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар калдыгын куллану тәртибе.

4.3. Муниципаль район бюджетына әлеге тәртипнең 2 пунктында каралган очракларда башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү әзерләү авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 5. Башка бюджетара трансфертлардан файдалануны контрольдә тоту

5.1. Муниципаль район бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертлардан файдалануны контрольдә тоту авыл җирлегенә финанс чараларыннан файдалану турында хисап бирү юлы белән гамәлгә ашырыла. Хисап бирүнең вакытлылыгы һәм формасы килешү белән билгеләнә.

5.2. Килешүдә каралмаган максатларда башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелгән акчаларны тоту рөхсәт ителми.

5.3. Финанс чараларын максатчан файдаланмаган очракта, алар авыл җирлеге бюджетына килешүдә билгеләнгән срокларда кире кайтарылырга тиеш.

5.4. Муниципаль район Башкарма комитеты башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

Муниципаль район бюджетына
башка бюджетара трансфертларны
бирү тәртибенә кушымта

20___ елның ________________________________________________
муниципаль район бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертларны тоту турында хисап

(сумнарда)

| Чараның исеме | Ел башыннан җирлек бюджетыннан кергән | Ел башыннан муниципаль район тарафыннан тотылган |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| Барлыгы: | | |

Җитәкче ______________________ ________________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Баш бухгалтер ______________________ ________________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

«____»_______________20______ ел.